Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«08 » декабрь, 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Главами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 45,69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлегенең 30.10.2019 ел 9/2 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда граждданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары нигезендә Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );
-торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формалары , балалар өчен уен, спорт җиһазлары, вазоннар, коймалар, хуҗалык блогы, балалар мәйданчыгын каплау өчен ком сатып алу,махсус аренда. техника, материаллар сатып алу).

2. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Р.Закиров

Исполнительный комитет Калмиинского сельского поселения
ОГРН 1061682004890
ИНН 1639032329